КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15.11.2023 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына таянып, 2023 елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2024 нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Юлбат торак пункты чикләрендә вак таш белән капланган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларындагы чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 332 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 173 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 173 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2024 нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Юлбат торак пункты чикләрендә вак таш белән капланган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларындагы чокырларны ремонтлау (вак

таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев